ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.11.2025 Олы Кайбыч ав. № 519

Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 22 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең социаль гарантияләрен тәэмин итү максатларында һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 2025 елның 27 октябрендәге 03-12/7278 номерлы хаты нигезендә, Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турында» 2019 елның 22 апрелендәге 190 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм шартлары турындагы нигезләмәгә (2022 елның 07 февралендәге 57 номерлы, 2024 елның 12 гыйнварындагы 8 номерлы, 2024 елның 25 апрелендәге 151 номерлы, 2024 елның 08 ноябрендәге 403 номерлы, 2025 елның 22 апрелендәге 196 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының үзәкләштерелгән бухгалтериясе» муниципаль учреждениесе җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазыйфаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазифасы | Вазыйфаи оклад, сум |
|---|---|
| | Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе | 40 700 |
| Муниципаль учреждение җитәкчесе урынбасары | 38 100 |
| Бүлек башлыгы | 33 600 |
| Әйдәп баручы бухгалтер | 30 600 |
| Бухгалтер | 29 000 |

Муниципаль учреждение булган үзәкләштерелгән бухгалтерияне штат расписаниесенә кертү шарты булып, җитәкче урынбасарының вазыйфасы структурада штат саны кимендә 5 берәмлек булган кимендә 3 бүлек булу тора.

Үзәкләштерелгән бухгалтерия бүлекләрендә штат саны кимендә 5 берәмлек булырга тиеш.».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында» бастырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче А.Н.Макаров